

# Җырланмаган җыр, ясалмаган портрет хакында

**Рөстәм Яхин турында консерваториядә әзерләнә торган китаптан бер сәхифә.**

Рөстәм әфәнде Яхин исеме, ничек кенә сәер тоелмасын, минем өчен иң әүвәл Себер яклары белән бәйле. Безгә аның үзен, матур аһәңле әсәрләрен илленче елларда Тобол татар педучилищесындагы җыр һәм музыка укытучыларыбыз — сөргеннәрдән торып калган ике зат: Нина Андреевна Филипович (Немирович-Данченколар сеңлесе, Н. А. Шпиллерның укытучысы) һәм Көнбатыш Украинадан скрипкачы Андрей Иванович Пахолкив ачтылар.

Россиянең каторга капкасы саналган Тоболда гаҗәеп матур агач бина — рус драма театры бинасы бар иде, хәзер ул юк инде, янды. Шунда ямьле яз айларында шәһәр яшьләренең сәнгать олимпиадасы була иде. Берсендә мин дә катнаштым. Рөстәм Яхинның Г. Тукай сүзләренә язылган "Кем белер кадереңне?" романсын җырлап, икенче урынны алу насыйп булды. Нина Андреевна рояльдә, Андрей Иванович скрипкада уйнап ярдәм итеп тордылар. Бөек шагыйребез дәһасен үз талант кодрәтенә буйсындырып, композитор Рөстәм Яхинның татар музыка сәнгатендә нинди "энҗе бөртеге" тудыруын без ул чагында, ихтимал, аңлап та җиткермәгәнбездер. Без бары аның "Онытa алмыйм", "Серле күзләр", "Ак җилкән", "Китмә сандугач" һ. б. бик күп әсәрләрен яратучылар гына. Алдыбызда язгы якты өметләр — Казан, зур сәнгать, сәхнә, музыка дөньясы. Н. А. Филипович миннән көчле меццо-сопрано әзерләмәкче. Соңыннан ул "маска" ясый алмау кимчелегемнән дә артык зур фаҗига ясамыйча, җырның үзе түгел, аның турындагы гыйлем — фольклор дөньясына юнәлтеп бәхетле итте. Ә сәхнә күрке була алмас тышкы күренештән соңыннан Б. Урманче ниндидер эчке балкыш эзләп, портретлар язды.

Шул заманның онытылмас, якты хатирәләр нуры гомерем дәверендә матур бизәк булып торды, соңрак та миңа рәссам Бакый Урманче җәмәгате сыйфатында композитор Рөстәм Яхинның үзен күрү һәм шактый еллар аралашып яшәү язган икән.

Бервакыт ул берничә композитор белән бергә Б. Урманче остаханәсенә Фәрит Яруллин бюстен "танырга", кабул итәргә килгән иде. Һәм Яруллин, һәм Сәйдәш, һәм Яхин ак мәрмәрдән чабыласы, Нәҗип Җиһанов бронзадан коеласы, дия иде Бакый Урманче. Әмма алдагы икесе ак гипста, Нәҗип Җиһановның 1956 елда Рузада ясалган портреты бронзага охшап тонлы гипста калды, аның һәм Ренат Еникеевның өчәр график портретларын ясады, Р. Яхин никтер һаман ясалмады. Әлеге килүләрендә мин көй осталарын чәй урынына мук җиләге суы (Себердә моро диләр) белән сыйлаган идем. Бәллүр касәдәге кызыл төсле тормыш эликсиры Рөстәм әфәнде Яхинга аеруча ошап калды. Себердәге тереклек җимеше, гомер-гомергә экспортка китүче табигый байлык — мук җиләге һәм ак бөрлегән (морак-морошка), ягъни яшәү көче бирүче, иҗат рухын күтәрүче эчемлекне дә мәңгеләштереп, нәкыш портретын ясауны да күз уңында тота иде Бакый ага. Әмма Р. Яхин портреты, башка берничә кешенеке кебек, планда, исемлектә генә торып калды.

Б. Урманченың 80 яше тулуга Р. Яхин Сәйфи Кудаш сүзләренә язылган бер романсын багышлап китергән иде. Аны өйдә Мөнирә ханым Булатова җырлады.

*Җырлачы бер, иркәм, яшь гомернең*
*Тәүге сөюләре турында.*
*Җырларыңны тыңлап, таңга хәтле*
*Мин утырыйм синең кырыңда.*

Бу матур романс та никтер сирәк яңгырый эфирда, сәхнәдән әле бөтенләй ишетелгәне юк бугай.

Элек Рөстәм әфәнде әнисе белән безнең тирәдә, Ленин районында торганда, Б. Урманче үзе дә аларда булгалаган, Мәрьям ханым белән мөлаем әңгәмәләре хакында сүз була иде. Соңыннан хаста хәлендә Чехов урамындагы шифаханәдә дә очрашкаларга туры килде аларга. Әмма сәнгать дигән бөек могҗизаның кеше күзенә күренмәс кануннары нәтиҗәседер

инде, композиторның үтә күренмәле самими йөз чалымнарына ни ак мәрмәргә кучү, ни ак кәгазьне бизәү насыйп булмаган, күрәсең.

Һәм менә тагы Себер белән бәйле моңсу бер сәхифә. Анда да сәнгатьнең без аңлап җитә алмаган юллары чагыла кебек.

1978 елда абыем Газиз Әхмәтовның 25 яшьлек угылы Маннур гади аппендициттан үлеп китте. Табиблар да гаепле, кырыс Себер шартлары да, әмма үлем үкенечсез булмый. Тетрәнгән ата йөрәгендә кайгы шигырь булып туган. Шуны "өйдә-тышта, урман-кырда йөргәнемдә авыз эченнән генә булса да шыңшып йөрерлек көйгә салмаслармы", дип, берәр композиторга бирүемне үтенгән иде.

*Кунак булдың бу дөньяда нигә бик аз?*
*Ник яшәдең болай яшьли үләр өчен?*
*Ник калдырдың безне тәмам бер бушлыкта,*
*Янып-көеп сине искә алыр өчен?*

Мин ул вакытта "Татар халык иҗаты" 12 томлык җыелмасының "Бәетләр" томын әзерли идем. Хәсрәт дәрьясы эчендә йөзү белән бергә, татар халкының көч-кодрәте, иман-куәтенә хәйран калам. Шулар турында Рөстәм әфәнде белән дә сөйләшүләр була иде. Ул әнисе Мәрьям ханымның ике вафат улы Әдһәм һәм Сәлимгә багышлап язган шигырьләре булуын әйтте. Соңыннан Хәлимә ханым Яхина аларны һәм үз әтисе Закир Таҗетдин бәетен безнең Институтка китереп тапшырды. Анисы "Бәетләр" томына кертелде, әниләре шигырьләрен мин фәнни мәкаләләремдә файдаландым. Биредә ул шигырьләрдән өзекләр китерүне тиеш табам.

### Әдһәм улы үлеменә

*Синең якты йөзең, мөлаем күзең*
*Карап тора минем каршымда.*
*Хәсрәтләрем бик зур, ни хәл итим,*
*Нинди бәхетсезлек башымда!*

### Сәлим улына.

*Кошлар килеп сайрый микән,*
*Балам, каберләреңә?*
*Кош сайраса, түзә алмыйм*
*Йөрәк бәгырьләремә.*

Рөстәм Яхин бер әсәрен Газиз Әхмәтов шигыренә дә язды. Аны М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры, Казан консерваториясе сәхнәләреннән Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бегичев башкарды. Төмән өлкәсеннән укытучы Газиз Әхмәтов махсус килде бу әсәр җырланасы концертка. Тыңлады, магнитофонга язып алып кайтып китте... Әмма ни үзе, ни туганнары иддә бу җырны җырлап йөрүче булмаганнар. Сәбәп ни, белмәдек. Рөстәм әфәндедән ни хак түлисе, дип сораугa, ул соң дәрәҗәдә гаҗәпләнде һәм "минем өчен әсәремнең җырланып йөрүе, кемнеңдер җанына рәхәт бирүе иң зур бәһа", — дигән иде. "Җырлана микән", — дип сораштырып та торды. Кире җавап алуга тын кала, берни дәшми иде.

Р. Яхинның үз вафатыннан соң бу әсәрне Хәлимә ханым әзрәк үзгәртеп, "Рөстәмебез" шәкелендә радиодан Мөнирә ханым Булатова тарафыннан да җырлаткан иде. Нәтиҗә шул ук. Югыйсә, шагыйрь Әхмәт Фәйзи үлгәннән соң һич көтмәгәндә "Умырзая"сы халык теленә кучеп, таралып, җырланып киткәндәй, бу хисси әсәр дә берәүләрне моңландырмый калмас дип көткән идем. Монда нәрсәдер җитмәде. Сүзләре — мөнәҗәтнеке, көе романсныкы төсле булуымы, әллә әнисе шигырьләрендәге кебек сәнгать көчеме. Аларга да көй язмаган бит әнә. Бәетләр мәгълүм бер көйләргә иҗат ителгән, билгеле бер шартларда — утырыш, махсус бәйгеләрдә башкарылган, алар сәхнә әсәре түгелдер, мөгаен. Ата-ана өчен бала үлеме, нәсел агачы киселүен күрү — дастаннар коллизиясе, шулар стихиясе дер, дип уйлыйм.

Кайвакыт гади сүзләр дә музыка һәм шигърияттән көчле тәэсир итә бит.

Мин Рөстәм әфәнде Яхин әсәрен Татарстан гимны дип тә кабул итүчеләрдән түгел. Иртә саен тыңлавымда ул рухландырмый, горурландырмый һәм көч бирми миңа. Бу турыда без, бер төркем фикердәшләр, заманында газеталәрдә дә язып чыккан идек. Татарстан парламенты аны аз күпчелек белән кабул итте (63 процент бугай, "Тәфтиләү"не матур итеп әзерләгәндә ул үтәсе иде. Булмады.).

Ахрысы, татар сәнгате Р.Яхинның лаеклы портреты, мәрсияви матур әсәре белән баеп кала алмавы да әлеге канунияте хөкемендә булган ахрысы, ягъни Ходай язмышыдыр.

Флора ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ.

Чыганак: **Сөембикә.- 1996.-№ 9**